| ГЛАВА МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| **02.11.2020 ел** | **№ 3** |

2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Мортыштамак авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елның 14 ноябрендә 11.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Колмәт авылы, Хисамов урамы, 9 нчы йорт адресы буенча урнашкан Колмәт авылы Мәдәният йорты бинасында 2021 елда Сарман муниципаль районының Колмәт авылы җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнарның җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Колмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортларының студентларыннан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүегез һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүегез белән килешәсезме:

1) Колмәт авылы территориясендәге чүп үләннәрен чабу һәм җыештыру (ягулык-майлау материаллары ,триммер)сатып алу;

2) Колмәт авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
3) Колмәт авылы тукталышына, тукталыш павильонын сатып алу һәм урнаштыру;
4) яңа юл билгеләре сатып алу һәм урнаштыру;
5) Колмәт авылында спорт ярышлары уздыру өчен призлар, бүләкләр сатып алу

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Мортыштамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы И.Н. Хадиуллин